Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының

Арча шәһәр муниципаль берәмлеге

Арча шәһәр

башкарма комитеты

422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының

Арча шәһәр муниципаль берәмлеге

Арча шәһәр

башкарма комитеты

422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

**от « 22 » ноябрь 2021 ел** **№ 246**

**«Агачлар, куаклар кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитетының 2021 ел, 17 нче август, 97 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча шәһәр башкарма комитеты карар бирә:

1. « Агачлар, куаклар кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга һәм кучереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында » Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Башкарма комитетының 17 август 2021 ел, №97 карары белән расланган газонны кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, агач, куаклар утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында "агачлар, куакларның авариясе турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга ;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында “гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне кисү зарурлыгы яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә расланмаган яки кирәк булмаган очракта (авария хәлендәге агачлар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында "авария-торгызу эшләре үткәрүгә бәйле яки яшел үсентеләрне кисү мөһим булган очраклардан тыш (агач төшү куркынычын бетерү өчен, авария хәлендәге агачлар) " сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 2.8.4 пунктында “2 нче кушымтада" сүзләрен “3 нче кушымтада” сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында “, шулай ук, авария-торгызу эшләрен үткәрү өчен яки яшел үсентеләрне кисү мөһим булганда, яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт алу белән мөрәҗәгать иткән очракта да (агач төшү куркынычын бетерү өчен, авария хәлендәге агачлар) " сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;

1.9. 3.5.5 пунктында «мөрәҗәгать итүче авария-торгызу эшләрен башкарганда яки яшел үсентеләрне кисү мөһим булганда муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта (агач төшү куркынычын бетерү өчен, авария хәлендәге агачлар)- ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.10. регламентның 2 нче кушымтасында " авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе — Р. Ф. Касыймов